# Яшьлек

Минзәлә шәһәре гимназиясе

Киләчәкнең башы - бүгенгедә

1998

*Нояб[illegible] ел*



## Атна шәхесе - Римма апа!



## Яшьләр берләшмәсе



## Әниләр көне

# Атна шәхесе -Римма апа!



Әлеге атнаның шәхесе уңган-булган, 4 бала әнисе, чибәр Римма апабыз! Ул безнең мәктәптә күптән түгел генә эшләсә дә, күп кенә балаларның йөрәген яулап алырга өлгерде инде.

**Туган көне:** 9.02.79
**Яраткан фильм:** күпчелек китап укый
**Яраткан китап:** психология жанры

**- Исәнмесез, Римма апа!**

- Исәнме, Айзилә.

**- Сезнең кумирыгыз бармы?**

- Кумир, хм... Юк. Әлегә андый кеше юк.



**- Сез үзегезне уңышлы кеше дип саныйсызмы?**

- Әлбәттә, мин иң уңышлы кеше, миннән дә уңышлырак кеше юк (көлә).

**- Әгәр “вакыт машинасы”на утырып үткәнгә кайтып булса, Сез ни дә булса үзгәртер идегезме?**

- Юк, миңа барысы да ошый. Мин бернине дә үзгәртмәс идем, ләкин үткәнгә кайтып булса, мәктәпкә эшләргә иртәрәк килер идем.



**- Сез бит әле 4 бала әнисе дә, вакытыгызны ничек барысына да җиткерәсез?**

- Хәзер инде 32 бала (көлә). Вакыт җитә, чөнки мин ярты көнемне хәзер алар белән мәктәптә үткәрәм. Айсылу кызым инде хәзер зур, аңа 18 яшь, ул барысын да үзе эшли.



**- Балаларыгыз тагын нинди өстәмә белем бирә түгәрәкләренә йөриләр?**

- Бию, фортепиано, гитара, баян.

**- Әгәр дә кеше яшәми торган утрауга эләксәгез, үзегез белән нинди 3 әйбер алыр идегез?**

- Казан, пычак, көрәк.

**- Сезнең тормышыңта берәр нинди уйланылмаган адым кылганыгыз булмадымы?**

- Ооо, күп, бик күп булды андый адымнар...



Җәмилова Айзилә

# Балалар берләшмәсе



СДО - нәрсә ул? Барыгыз да ишеткәнсездер СДО турында. Ләкин нәрсә соң ул?

Беренчедән, СДО - балалар оешмасын житәкли торган иң зур балалар оешмасының берсе.



Икенчедән, балаларга, яшүсмерләргә үзләрен табуда, шәхес буларак ачылуда ярдәм итә торган мохит. Ә моның өчен алар уңайлы мохит булдырырга омтылалар, барлык кирәкле һәм кызыклы өлкәләрдә эшлиләр:



- спорт һәм туризм
-эшмәкәрлек һәм эшкә урнашу
-социаль яклау һәм волонтерлык эшчәнлеге
-патриотик тәрбия
- балалар массакүләм мәгълүмат чаралары
- мәдәният һәм яшүсмерләрне ижади яктан үстерү
- балаларның һәм яшьләрнең хокук яклау, мәгариф
- экологик тәрбия



Моннан тыш, СДО – үзе өчен генә түгел, ә якыннары өчен дә җаваплылык алырга сәләтле чын лидерлар, шәхесләр өчен бу бик яхшы старт мәйданчыгы. Балалар елдан-ел халыкара, бөтенроссия һәм республика бәйгеләрендә җиңү яулыйлар. Ә иң мөһиме, аларда лидерлык сыйфатлары, командада эшләү тәҗрибәсе, сөйләм, ижади фикерләү барлыкка килә, һәм үзләренең эчке мөмкинлекләрен ачалар.



8 нче ноябрь көнне яшь гражданнар Форумы Минзәлә муниципаль районының иң актив егетләрен һәм кызларын берләштерде. Эш 9 юнәлеш буенча дустанә мохиттә узды. Форумның нәтиҗәсе буларак, районыбызны үстерү буенча балаларның 500 дән артык идеяләре билгеләнде, ә шуларның иң шәпләре пленар утырышта бертавыштан кабул ителгән форум резолюциясенә керде. Болар арасында безнең мәктәп укучылары да булды: актив катнашкан өчен грамота, йомгаклау өлешендә үз идеяңне күрсәтү мөмкинлеге белән бүләкләнделәр. Оештыручыларга рәхмәт белдере, форумның катнашучылары яхшы кәефтә кайтып киттеләр.

# Әниләр көне



Безнең мәктәптә гаилә гербы конкурсын игълан иттеләр. Нәрсә ясарга, гаиләбезнең нигезе нәрсәдә? Башта бик җайлы гына ясалыр сыман иде герб. Әни, әти, абыем һәм мин, җыелыштык, озак уйлаштык, киңәшләштек һәм, ниһаять, уртак фикергә килдек.

Хәзер сезне уртак җимешебез белән таныштырып үтәсем килә. Менә ул - безнең гаиләбезнең гербы! Үзәгендә - имән агачы. Аны әтием сайлады.“Имән - озын гомерне, ныклылыкны аңлата. Әйдәгез, без дә шулай көчле булып яшик! Имән тамыры ныклы булгандай, гаиләбезнең дә тамырлары



тирән һәм нык булсын”,- диде ул. Әнием: “Имән агачыннан ярату, хөрмәт итү, дуслык яфраклары коела”, дигәч, күңелем әллә нишләде. Әнием белән әтиемне кочаклап алдым. “Мин сезне бик яратам!”- дидем.



Гаиләбезнең тамырлары - әби-бабаларыгыз,- дип дәвам итте әнием. Чыннан да, һәр атна саен диярлек, без авылга - көчле тамыр ияләренә - әле әтием, әле әниемнең әти-әниләренә кайтабыз. Чөнки анда гына безгә күңелле, рәхәт, алар гына безне өзелеп, түземсезлек белән көтәләр. Мин якыннарымны бик хөрмәт итәм. Әтием ягыннан бабам Мансур, әбием Миңниса 45 ел бергә, безгә үрнәк булып, дус, тату яшиләр. Әнием ягыннан бабам Рәсим белән әбием Миңленур гаилә корып яшәүләренә 56 ел! Алар 4 бала тәрбияләп үстергәннәр, 7 оныклары арасында мин бар. Мине әбиемә бик охшаган, диләр. Дәү әнием кебек тыныч, ягымлы сөйләшергә өйрәнәм, өй эшләрен әбием сыман җитез башкарырга тырышам. Бүген аңа 80 яшь, ә ул күзлексез газеталар укый, йон оекбаш-бияләйләр бәйли. Мин әби-бабаларым белән горурланам!






Гаилә гербында кулларыбызны символ итеп куйдык. Чөнки, кулга-кул тотынышып, дус- тату яшибез, авыр вакытларда беребезне дә ялгыз калдырмыйбыз, һәрчак ярдәм итәргә генә торабыз. Куана да беләбез: бергәләшеп бәйрәмнәрдә күңел ачабыз, сый-хөрмәт күрсәтәбез.

Кулларның иң кечкенәсе - минеке. Мин зур үскәч, әнием белән әтиемә бик игътибарлы булырмын, кадерләп, хөрмәтләп торырмын- гаилә гербына тап төшермәм, аны буыннан-буынга тапшырырмын. Минем гаиләм - минем бәхетем.



Галиева Сылу

# Безнең киләчәк



Һәр ел безнең мәктәптә, укучыларга киләчәк профессия сайларга булышу максаты белән, профориентация дәресләре үткәрелә. Бу дәресләр безгә һөнәрне җайлырак сайларга, безнең көчлерәк якларны ачыкларга, һәм безгә туры килгән юнәлешне табарга ярдәм итә.



Бу уку елының һәр атнасының шимбә көнендә 9 нчы сыйныфларда профиль дәресләре үткәрелде. Аны үткәрергә педагогия көллияте педагогы Илгизә Муфасталовна ярдәм итте. Ул педагогика үзенчәлекләрен, укытучы профессиясенең детальләрен, уңайлы һәм уңайсыз якларын сөйләде. Моннан тыш ул безгә көллият-тә урнашкан Муса Җәлил музеена сәяхәт оештырды, көллиятнең директорлары шәҗәрәсе тарихын сөйләп бирде. Шулай ук иҗади биремнәре булган төрле кызыклы дәресләр узды.



Әлеге профиль дәресләре, чыннан да, һөнәр сайлауда бик файдалы булды, арабызда көллияткә укырга барырга теләүчеләр дә табылды.

Шул ук профиль эчендә 9 нчы сыйныф укучыларына бер дәрес дәвамында үзен укытучы ролендә хис итү мөмкинлеге дә бирелде. Алар 3 нче сыйныфта Әниләр көненә багышланган дәрес үткәрделәр: балаларны оригами-чәчәк ясарга өйрәттеләр. 3 нче сыйныф балалары дәрестән бик канәгать калдылар, 9 нчы сыйныф укучыларына да балалар белән эшләү бик ошады.



Мондый



дәресләр,чыннан да, профессия сайлауда ярдәм итәләр. Һөнәргә юнәлеш бирүгә ба-гышланган чараларны даими үткәрергә кирәк дип уйлыйбыз.



*Сәхәбетдинова Регина*

# Туган көн- гомер бәйрәме...



**Укытучылар:**
**Роза Александр кызы (01.11)**
**Фирдәвис Гаптеләхәт кызы (5.11)**
**Лариса Рафаэль кызы (11.11)**
**1 нче сыйныф:**
**Сәлимгәрәева Әмирә (22.11)**
**Зыатдинова Азалия (14.11)**
**2 нче сыйныф:**
**Зарипова Самира (6.11)**
**Закиров Илдан (8.11)**
**Гарипова Диләрә (12.11)**
**Нуриева Ләйсирә (13.12)**
**3 нче сыйныф:**
**Ханова Данияр (4.11)**
**Мөхәммәтова Алинә (5.11)**
**4 нче сыйныф:**
**Нуруллина Гөлназ (2.11)**
**Хәмидов Ислам (14.11)**
**5 нче сыйныф:**
**Сабитова Руфинә (15.11)**
**Әхмәтшин Адель (28.11)**
**6 нчы сыйныф:**
**Нуриев Ислам (26.11)**
**7 нче сыйныф:**
**Шәфыйкова Алинә (3.11)**
**Сабитов Айнур (19.11)**
**8 нче сыйныф:**
**Әминов Альмир (17.11)**
**Хәсәнова Илгизә (29.11)**
**9 нчы сыйныф:**
**Равылова Айсылу (20.11)**
**10 нчы сыйныф:**
**Минникаев Нияз (21.11)**
**11нче сыйныф**
**Зиннуров Булат (24.11)**







**Баш мөхәррир** —Низамова Сөмбел
**Әдәби консультант-** Җәмилова Айзиля
**Бүлек мөхәррирләре** - Хәбирова Наилә
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Галиева Лилия Альберт кызы, Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745